Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Гаделша авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

14.12.2023 ел № 42/3

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Гаделша авыл җирлеге Советының
2019 елның 5 июнендәге «Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Гаделша авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында»гы
68/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2023 елның 02 ноябрендәге N 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Гаделша авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 05.06.2019 елның 36/1 номерлы Гаделша авыл җирлеге советы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Гаделша авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәнең 6 статьясына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

17 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"20. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган классլы чиннар бирү турында тапшыру кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Гаделша авыл
җирлеге башлыгы Ф.Х.Сабирҗанов